ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 май 2020ел № 2336

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 2 июлендәге 546 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм түләтү тәртибен, 2 нче кушымтада каралганча;

3) Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибен, 3 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның 2014 елның 30 июлендә «Челнинские известия» газетасының 55 нче санында басылып чыккан «Шәһәрнең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча эшчәнлекне норматив финанслау турында» 2014 елның 17 июлендәге 4225 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2336 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында
тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (алга таба – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы) балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны формалаштыру механизмын билгели.

2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны (алга таба – норматив чыгымнар) исәпләү тәртибе мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына кагыла.

3. Норматив чыгымнар елына бер тәрбияләнүчегә исәпләп билгеләнә.

2 бүлек. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында
балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив
чыгымнарны исәпләү тәртибе

3. Норматив чыгымнарга түбәндәгеләр керә:

1) балаларны карауны һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды;

2) туклануны һәм азык-төлек сатып алуны оештыру чыгымнары;

3) тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу чыгымнары;

4) тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары;

5) тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары.

5. Норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$NSV^{t}_{vxyz} = FOT^{t}_{vxyz} + R_{xyzpit} + R_{vybo} + R^{t}_{vzmo} + R_{vyobes},$$

монда:

$NSV^{t}_{vxyz}$ - норматив чыгымнар;

$FOT^{t}_{vxyz}$ - карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды;

$R_{xyzpit}$ – туклануны оештыру чыгымнары;

$R_{vybo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу чыгымнары;

$R^{t}_{vzmo}$ - тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары;

$R_{vyobes}$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары.

t - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр җирлеге);

v - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төркеме;

z - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең яшь составы;

x - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының бер атнага эш көннәре саны (мәктәпкәчә белем бирү оешмасындагы төркемнәр);

y - балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында (мәктәпкәчә белем бирү оешмасындагы төркемдә) булу вакытының озынлыгы.

6. Аз комплектлы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$NSV^{t}_{vxyzm} = \left(FOT^{t}_{vxyz} + R_{vybo} + R^{t}_{vzmo} + R_{vyobes}\right) \times \frac{m_{vzlim}}{2} + R_{xyzpit} \times m_{ivxyz},$$

монда:

$NSV^{t}_{vxyzm}$ - аз комплектлы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында норматив чыгымнар;

$FOT^{t}_{vxyz}$ - карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды;

$R_{vybo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу чыгымнары;

$R^{t}_{vzmo}$ - тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары;

$R_{vyobes}$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары;

$m_{vzlim}$ – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең норматив саны;

$R_{xyzpit}$ - туклануны оештыру чыгымнары;

$m_{ivxyz}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең фактгагы саны.

7. Балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды түбәндәге параметрлардан чыгып исәпләнә:

1) мәктәпкәчә белем бирү оешмасында төркемнең тулылык чиге;

2) персоналның эш вакытының норматив озынлыгы;

3) мәктәпкәчә белем бирү оешмасының (мәктәпкәчә белем бирү оешмасындагы төркемнең) бер атнада эш көннәре саны:

4) алты көнлек эш атнасы;

5) биш көнлек эш атнасы;

6) балаларның төркемдә булу вакыты озынлыгы.

8. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT^{t}_{vxyz} = \sum_{i=1} N_{vziq} \times O_{tiq} \times e \times 12,$$

монда:

$FOT^{t}_{vxyz}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның хезмәтенә түләү фонды;

$N_{vziq}$ - балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персонал ставкалары саны;

$O_{tiq}$ – хезмәт хакы чыгымнары;

e – иминият взносларының күләме;

12 – елдагы айлар саны;

v – мәктәпкәчә белем бирү оешмасындагы төркем;

t - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр җирлеге);

z - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең яшь составы;

i - карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы персоналның вазыйфалары;

q - тәрбияләнүчеләрнең категориясе.

9. Туклануны оештыру чыгымнары түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эш режимын төзүгә, карап тотуга һәм оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.4.1.3049-13 СанПиН раслау турында» 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карары нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрнең туклану нормалары;

2) чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, планнан алда булган елның 1 сентябренә торышы буенча азык-төлек товарларының уртача базар бәясе.

10. Туклануны оештыру чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_{xyzpit} = C_{xyzpit} \text{ x } K_{y\ pit},$$

монда:

$R_{xyzpit}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында туклануны оештыру чыгымнары;

$C_{xyzpit}$ – елына бер тәрбияләнүчегә азык-төлек чыгымнары;

$K_{y\ pit}$ – балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында булу вакыты озынлыгы коэффициенты (3-4 сәгать булу срогы белән кыска сроклы төркемнәр өчен – 0,25, 5-6 сәгать булу срогы белән – 0,6, калган төркемнәр өчен 1 гә тигез дип кабул ителә).

11. Азык-төлек чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_{xyzpit} = D_x \times \sum_{i_3=1}^{n_3} N_{i_3\ yzpit} \times C_{i_3pit},$$

монда:

$C_{xyzpit}$ – азык-төлек чыгымнары;

$D_x$ – бер тәрбияләнүченең бер елда мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булу көннәренең уртача саны (биш көнлек эш режимы булган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында – 220 көннән, алты көнлек эш режимы булганнарында - 270 көннән арттырмыйча кабул ителә);

$N_{i_3\ yzpit}$ - тәрбияләнүчеләрнең туклану нормалары;

$C_{i_3pit}$ - тәрбияләнүчеләрнең туклану продуктлары исемлегенә керә торган азык-төлек товарларының бәясе;

$n_3$ - тәрбияләнүчеләрнең туклану продуктлары исемлегенә керә торган азык-төлек товарларының саны;

$i_3$ - тәрбияләнүчеләрнең туклану продуктлары исемлегенә керә торган азык-төлек товарының (продуктның, ашамлыкның) исеме.

12. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары үз эченә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләрен сатып алуга агымдагы чыгымнарны ала.

13. Тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары расланган нормативлар буенча түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) әлеге кагыйдәләрнең 1 нче, 2 нче таблицаларында каралганча кабул ителә торган хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу нормалары;

2) чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, план елыннан алдагы елның 1 сентябренә торышы буенча хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алуның уртача базар бәясе.

1нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләрен сатып алу нормалары

| Хезмәтнең исеме | Норманы үлчәү берәмлеге | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булу вакытына карап, бер тәрбияләнүчегә елына норма | |
|---|---|---|---|
| | | 7 - 12 сәгать | 24 сәгать |
| Кер юу хезмәте | Коры кернең бер килограммы | 60 | 120 |

2 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында
тәрбияләнүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге
товарлар сатып алу нормалары

| N т/с | Предметның исеме | Норманы үлчәү берәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|---|
| 1. | Кер сабыны | кг | 2 |
| 2. | Бәдрәф кәгазе | төргәк | 1,5 |
| 3. | Кер юу порошогы | кг | 2,4 |
| 4. | Кальцийлаштырылган сода | кг | 0,5 |
| 5. | Хлорамин | кг | 0,7 |

14. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_{vybo} = \sum_{i_4=1}^{n_4} N_{i_4\ y\,ybo} \times C_{i_4 ybo} \times K_{y\ ybo} + \sum_{i_5=1}^{n_5} N_{i_5\ y\,tbo} \times C_{i_5 tbo} \times K_{y\ tbo},$$

монда:

$R_{vybo}$ – тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу чыгымнары;

$N_{i_4\ y\,ybo}$, $N_{i_5\ y\,tbo}$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар сатып алу нормалары;

$C_{i_4 ybo}$, $C_{i_5 tbo}$ - хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре, хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар бәясе;

$n_4$, $n_5$ - хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре, хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарлар саны;

$i_4$, $i_5$ - тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтенең, хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге товарларның исеме;

$K_{y\ ybo}$ – балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булу вакытында хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләрен куллану күләмен исәпкә ала торган корректировкалау коэффициенты (3-6 сәгать булу срогы белән кыска сроклы төркемнәр өчен – 0 гә, калган төркемнәр өчен 1 гә тигез дип кабул ителә);

$K_{y\ tbo}$ - балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булу вакытында хуҗалык-көнкүреш товарларын куллану күләмен исәпкә ала торган корректировкалау коэффициенты (3-6 сәгать булу срогы белән кыска сроклы төркемнәр өчен – 0,5 кә, калган төркемнәр өчен 1 гә тигез дип кабул ителә).

15. Тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары үз эченә медикаментлар һәм бәйләү чаралары сатып алуга агымдагы чыгымнарны ала.

16. Тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары расланган нормативлар нигезендә түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) медикаментлар һәм бәйләү чаралары сатып алу нормалары, әлеге кагыйдәләрнең 3 нче таблицасында каралганча;

2) чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, план елыннан алдагы елның 1 сентябренә торышы буенча медикаментлар һәм бәйләү чараларының уртача базар бәясе.

3 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне медикаментлар һәм бәйләү чаралары белән тәэмин итү нормалары

| N т/с | Медикаментның исеме | Үлчәү берәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бактерицид лейкопластырь 6 x 10 | данә | 2,5 |
| 2. | Медицина термометры | данә | 0,5 |
| 3. | Стериль булмаган бинт 7 x 14 | данә | 6 |
| 4. | «Ревит» поливитаминнары № 50 | кап | 1,5 |
| 5. | Нашатырь спирты 10% - 40,0 | флакон | 0,5 |
| 6. | Активлаштырылган күмер 0,25 № 10 | кап | 2,5 |
| 7. | Спиртлы йод эремәсе 5% - 10,0 | флакон | 0,5 |
| 8. | Хирургия мамыгы | кг | 0,5 |
| 9. | Калий перманганаты 3,0 | флакон | 0,5 |
| 10. | Парацетамол 0,2 № 10 | кап | 1,5 |
| 11. | Яшел бриллиант эремәсе 1 % - 100,0 | флакон | 0,5 |
| 12. | Борлы спирт 3 % - 10 | флакон | 1,5 |
| 13. | Нафтизин 0,1 % - 10,0 | флакон | 1,5 |
| 14 | Аскорбин кислотасы № 200 | кап | 2 |

17. Тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R^{t}_{vyz\ mo} = \sum_{i_6=1}^{n_6} N_{i_6\ mo} \times C_{i_6\ mo},$$

монда:

$R^{t}_{vyz\ mo}$ тәрбияләнүчеләргә санитар-гигиена хезмәте күрсәтүне тәэмин итү чыгымнары;

$N_{i_6\ mo}$ - медикаментлар һәм бәйләү чаралары сатып алу нормалары;

$C_{i_6\ mo}$ - медикаментлар һәм бәйләү чараларының бәясе;

$n_6$ - медикаментлар һәм бәйләү чараларының саны;

$i_6$ - медикамент һәм бәйләү чарасының исеме.

18. Тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары түбәндәгеләргә нигезләнеп билгеләнә:

1) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү нормалары, әлеге кагыйдәләрнең 4 нче таблицасында каралганча;

2) чираттагы финанс елына шәһәр бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, планнан алда булган елның 1 сентябренә торышы буенча азык-төлек булмаган товарларның уртача базар бәясе.

4 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү нормалары

| N т/с | Предметның исеме | Норманы үлчәү берәмлеге | Елына бер тәрбияләнүчегә норма |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Балалар тастымалы | данә | 2 |
| 2. | Салфетка | данә | 1 |
| 3. | Тышкы мендәр тышы | данә | 1 |
| 4. | Эчке мендәр тышы | данә | 0,25 |
| 5. | Җәймә | данә | 0,7 |
| 6. | Юрган тышы | данә | 0,7 |
| 7. | Мендәр | данә | 1 |
| 8. | Матрац | данә | 0,2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Җылы юрган | данә | 0,2 |
| 10. | Байкадан тегелгән юрган | данә | 0,2 |
| 11. | Йокы капчыгы | данә | 0,25 |
| 12. | Өстәл ашъяулыгы | данә | 0,12 |
| 13. | Савыт-саба тастымалы | данә | 0,2 |
| 14. | Өстәл клеенкасы | кв. метр | 0,3 |

19. Тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_{vyobes} = \sum_{i_7=1}^{n_7} N_{i_7\ inv} \times C_{i_7\ inv} \times K_{y\ inv},$$

монда:

$R_{vyobes}$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү чыгымнары;

$N_{i_7\ inv}$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итү нормалары;

$C_{i_7\ inv}$ - йомшак инвентарьнең бәясе;

$K_{y\ inv}$ - балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булу вакыты озынлыгының коэффициенты (3-6 сәгать булу срогы белән кыска сроклы төркемнәр өчен – 0 гә, калган төркемнәр өчен 1 гә тигез дип кабул ителә);

$n_7$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итүнең билгеләнгән нормалары исемлегендә товарлар саны;

$i_7$ - тәрбияләнүчеләрне йомшак инвентарь белән тәэмин итүнең билгеләнгән нормалары исемлегендә товарлар исеме.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2336 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм түләтү
тәртибе

1 бүлек. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында
балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвен исәпләү,
раслау һәм үзгәртү тәртибе

1. Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында (алга таба – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы) балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмасында тәрбияләнүче бер балага, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркеменең юнәлешенә бәйле рәвештә билгеләнә.

2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-ана түләвенең күләме үз эченә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү чыгымнарын ала.

Катнаш һәм сәламәтләндерү юнәлешләрендәге төркемнәргә йөрүче балалар өчен ата-ана түләвенең күләме гомуми үстерелешле юнәлештәге төркемнәргә йөрүче балалар өчен ата-ана түләве дәрәҗәсендә билгеләнә.

Өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләр өчен ата-ана түләвенең күләме 50 процентка киметелә.

3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче инвалид балаларны, ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикацияле балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве алынмый.

4. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, тәрбияләнүче мәктәпкәчә белем бирү оешмасында булмаган чорда, ата-ана түләве тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнары зурлыгына киметелергә тиеш. Тәрбияләнүчеләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнарының зурлыгы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең норматив чыгымнарына кертелә торган азык-төлек сатып алу чыгымнары зурлыгына тигез итеп кабул ителә.

5. Тәрбияләнүче мәктәпкәчә белем бирү оешмасыннан киткән очракта мәктәпкәчә белем бирү оешмасында агымдагы айның ата-ана түләве кире кайтарылмый.

6. Тәрбияләнүче бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчерелгәндә мәктәпкәчә белем бирү оешмасында агымдагы айның калган көннәренә ата-ана түләве, тәрбияләнүче күчерелгәннән соң, кире кайтарылырга тиеш.

7. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-ана түләвенең күләмендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләүгә

карый торган чыгымнар, шул исәптән ата-ана түләве исәбенә каплана торган азык-төлек бәясе аерып күрсәтелергә тиеш.

8. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар зурлыгы билгеләнгән тәртиптә үзгәргән очракта, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында гамәлдәге чор дәвамында ата-ана түләвенең күләме вакытыннан алда яңадан каралырга тиеш.

## 2 бүлек. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-ана түләвен алу тәртибе

9. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында ата-ана түләве ай саен, агымдагы айның унынчы числосыннан да соңга калмыйча кертелә.

10. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында ата-ана түләве, билгеләнгән вакыттан соң ике атна эчендә кертелмәгән очракта, күрсәтелгән сумма законда каралган тәртиптә түләтелә.

11. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында артык кертелгән ата-ана түләве тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә гариза бирүе нигезендә кире кайтарыла, ул түләү керткән көннән башлап бер ел тулганчы бирелергә мөмкин.

12. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында артык кертелгән ата-ана түләве, тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә гариза биргән көннән башлап ике атна эчендә кире кайтарыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2336 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмасын
финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү
тәртибе

1. Әлеге тәртип муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасын (алга таба – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыруга һәм тәрбияләнүчеләрне карап тотуга финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү механизмын билгели.

2. Әлеге тәртип мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының түбәндәге төркемнәренә кагыла:

1) гомумүстерешле юнәлештәге;
2) компенсацияләү юнәлешендәге;
3) катнаш юнәлештәге;
4) сәламәтләндерү юнәлешендәге.

3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FODS^{t}_{i\,vxyz} = \sum^{n_9} \begin{pmatrix} m_{vz\,lim} \times k_{mi\,vxyz} \times g_{i\,vxyz} \times \left(NFZ^{t}_{vz} + \left(NSV^{t}_{vxyz} - C_{xyzpit}\right)\right) + \\ + C_{xyzpit} \times m_{ivxyz} - RP^{t}_{vxyz} \times \left(m_{ivxyz} - m^{100\%}_{vxyz}\right) - RP^{t}_{vxyz} \times 0{,}5 \times m^{50\%}_{vxyz} \end{pmatrix} +$$
$$+ NSI^{t}_{vi} + K^{t}_{i\,v} + Cn_{i} + Tr_{i},$$

монда:

$FODS^{t}_{i\,vxyz}$ - i мәктәпкәчә белем бирү оешмасын финанс белән тәэмин итү күләме;

$m_{vz\ lim}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең норматив саны;

$k_{mi\ vxyz}$ - балаларның i мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемнәренә йөрүләрен исәпкә ала торган корректировкалау коэффициенты ( $m_{i_{vxyz}} < 0{,}5 \times m_{vz_{lim}}$ булганда - 0,9 га, калган очракларда 1 гә тигез дип кабул ителә);

$g_{i\ vxyz}$ - i мәктәпкәчә белем бирү оешмасында төркемнәр саны;

$NFZ^{t}_{vz}$ - нормативларның зурлыгы;

$NSV^{t}_{vxyz}$ - норматив чыгымнар;

$C_{xyzpit}$ – бер елга азык-төлек чыгымнары;

$m_{ivxyz}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең факттагы саны;

$RP^{t}_{vxyz}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең күләме;

$m_{vxyz}^{100\%}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында балаларны карап тоту өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмасында ата-ана түләве алынмый торган тәрбияләнүчеләрнең факттагы саны;

$m_{vxyz}^{50\%}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасында карап тоту өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмасында ата-ана түләвенә 50 процент ташламага ия тәрбияләнүчеләрнең факттагы саны;

$NSI_{vi}^{t}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнар;

$K_{iv}^{t}$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнары;

$Cn_i$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының элемтә хезмәтләренә чыгымнары;

$Tr_i$ - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының бассейнны карап тотуга чыгымнар зурлыгы;

n9 - мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш режимнары саны (мәктәпкәчә белем бирү оешмасындагы төркемнәр).

4. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында тәрбияләнүчеләрнең һәм төркемнәрнең саны планлаштырыла торган елдан алдагы елның 1 сентябренә торышы буенча кабул ителә.

5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар нормативлары, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында азык-төлек чыгымнары нормативлары, мәктәпкәчә белем бирү оешмасында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең күләме ел саен Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова